# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

1996 елга Татарстан Республикасының
бюджет системасы турында

1 статья. 1996 елга Татарстан Республикасының республика бюджетын чыгымнар буенча - 7310535 млн.сум күләмендә һәм керемнәр буенча 5840727 млн.сум күләмендә билгеләргә.

1996 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты кытлыгының иң чик күләмен 1469808 млн.сум яисә 1996 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты чыгымнарына карата 20 процент дип билгеләргә.

2 статья. 1996 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты керемнәре өстәлгән бәяләргә салым, акцизлар, предприятиеләрдән һәм оешмалардан табышка салымның бер өлеше, физик затлардан керем салымының бер өлеше, башка керемнәр һәм җыемнар бәрабәренә барлыкка килә дип билгеләргә.

3 статья. Җир өчен салым ставкалары 1996 елның 1 гыйнварена гамәлдә булган ставкаларга карата 1,2 коэффициенты белән кулланыла дип билгеләргә.

4 статья. Файдалы казылмаларны чыгарган өчен түләүләрнең ставкаларын чыгарылган табигый байлыкны сатудан килгән бәяләргә карата түбәндәге процентларда билгеләргә (моңа өстәлгән бәяләргә салым һәм акцизлар керми):

| Файдалы казылмаларның (чималның) төрләре | Ставка |
|---|---|
| 1. Нефть һәм газ | 8 |
| 2. Табигый битум | 4 |
| 3. Гипс ташы | 4 |
| 4. Фосфоритлар | 4 |
| 5. Цемент чималы | 4 |

| | |
|---|---|
| 6. Туфракны известьлау өчен карбонат токымнары | 3 |
| 7. Карбонат токымнары | 3 |
| 8. Киселгән таш | 3 |
| 9. Бут һәм вак таш өчен тәзелеш ташы | 3 |
| 10. Ком-гравий катнашмасы | 4 |
| 11. Пыяла һәм формалау комы | 4 |
| 12. Төзелеш комы | 3 |
| 13. Бентонит балчыклары | 4 |
| 14. Керамзит балчыклары | 4 |
| 15. Кирпеч балчыклары | 2.5 |
| 16. Глауконитлар, цеолитлар | 4 |
| 17. Торф, торфовивианит | 3 |
| 18. Җир асты сулары | 6 |

5 статья. 1996 елда җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр бюджет кимәлләре буенча түбәндәгечә бүленә дип билгеләргә (%):

| Түләүләрнең төрләре | Бюджетлар буенча бүленеш | |
|---|---|---|
| | республика | районнар (шәһәрләр) |
| 1. Файдалы казылмаларны чыгарган өчен түләүләр | - | - |
| - торф, сапропель, җир асты сулары һәм шифалы сулар буенча; | - | 100 |
| - киң таралган файдалы казылмалар буенча; | - | 100 |

| | | |
|---|---|---|
| - нефть, газ, Идел һәм Кама елгалары үзәннәреннән чыгарылучы ком-вак таш катнашмасы, табигый битум, гипс ташы, цемент чималы буенча; | 70 | 30 |
| - файдалы казылмаларның калган төрләре буенча (фосфоритлар, бентонит балчыклары, керамзит балчыклары, төзелеш известе өчен карбонат токымнары, киселгән таш, пыяла һәм формалау комы, глауконитлар, цеолитлар) | - | 100 |
| 2. Файдалы казылмаларны лицензияләрдә билгеләнгән лимитлардан (квоталардан) тыш кулланган өчен түләүләр, 5 мәртәбәгә артыграк ставка буенча алына; | 60 | 30 |
| - нормативлардан тыш кулланылыш билгеләнгән орган исәп-хисабына - 10% | | |
| 3. Файдалы казылмаларны чыгаруга бәйле булмаган җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр | 50 | 50 |

<u>6 статья.</u> Татарстан Республикасы бюджетына кертелүче табышка салым ставкасын түбәндәгечә билгеләргә:

а) предприятиеләр, оешмалар һәм читилләрнең хокукый затлары өчен - 22 процент күләмендә;

б) биржалар, брокер конторалары, кредит һәм иминләштерү оешмалары, предприятиеләр өчен - арадашчы гамәлләреннән, килешүләреннән алынган табыш буенча - 30 процент күләмендә.

235



7 статья. Керемнәргә салымнар буенча түбәндәге ставкалар билгеләргә:

а) предприятиеләр һәм оешмалар карамагындагы акцияләр, облигацияләр һәм башка чыгарылган кыйммәтле кәгазьләр буенча килгән дивидендлардан, процентлардан (моңа дәүләт облигацияләреннән һәм башка кыйммәтле дәүләт кәгазьләреннән килгән керемнәр керми) - 2 процент күләмендә, ә кредит оешмаларының күрсәтелгән керемнәренә - 5 процент күләмендә;

б) видеосалоннардан (видеокүрсәтүләрдән), видео- һәм аудиокассеталар прокатыннан, шулай ук аларга язырулардан - 57 процент күләмендә;

в) казинолардан, башка тәр уен йортларыннан (урыннарыннан) һәм башка тәр уен бизнесыннан - 77 процент күләмендә.

8 статья. Су хуҗалыгы системасыннан сәнәгать предприятиеләре ала торган су өчен 1995 елның 31 декабренә гамәлдә булган түләүләр 2 коэффициенты белән кулланыла дип билгеләргә.

9 статья. "1995 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында" Татарстан Республикасы Законының 10 статьясының гамәлдә булуын 1996 елга озынайтырга.

10 статья. Предприятиеләрнең һәм оешмаларның мөлкәтләренә салым буенча ставкаларны 1996 елның 1 кварталына салым салу базасының 3 проценты күләмендә билгеләргә, моңа "АлАЗ" җитештерү берләшмәсе керми. "АлАЗ" җитештерү берләшмәсе мөлкәтенә салым буенча ставканы салым салу базасының 0,1 проценты күләмендә билгеләргә.

1996 елга физик затларның мөлкәтләренә салым ставкаларын корылмаларны, биналарны һәм төзелмәләрне инвентаризация күлегеннән бәяләүдән 0,1 процент күләмендә билгеләргә.

11 статья. 1996 елга Татарстан Республикасының республика бюджетына төп чыганаклар буенча керемнәрнең килерен түбәндәге суммаларда дип исәпкә алырга:

(млн.сумнарда)

| | |
|---|---|
| Предприятиеләр һәм оешмалар табышына (керемена) салым | 1074401 |
| Физик затлардан керем салымы | 196289 |
| Өстәлгән бәяләргә салым | 1436000 |
| Акцизалар | 1113696 |
| Табигый байлыклардан файдаланган өчен түләүләр | 245880 |
| Жир өчен түләүләр | 51724 |
| Башка салымнар, җыемнар һәм үзгә килерләр | 270208 |
| Мөлкәткә салым | 249529 |
| Дәүләт пошлинасы | 7700 |
| Халык хуҗалыгының мөһим тармакларына ярдәм итү өчен предприятиеләрдән, учреждениеләрдән һәм оешмалардан алынучы махсус салым | 23000 |
| Хосусыйлаштырудан керемнәр | 29300 |
| Татарстан Республикасының кыска вакытлы республика облигацияләрен сатудан керемнәр | 383000 |

1995 елда кире кайтару шарты белән бирелгән акчалар керемнәре 746000

Кыйммәтле кәгазьләр белән бәйле гамәлләргә салым 14000

12 статья. 1996 елда районнарның һәм шәһәрләрнең бюджетларына түбәндәге салымнарны тапшырырга:

- предприятиеләрнең һәм оешмаларның табышына (керемнә) салым - салым салынучы табышның 22%ы күләмендә, ә кайбер районнарга һәм шәһәрләргә түбәндәгечә бирелә:

Азнакай районына- 3%, Азнакай шәһәренә - 9%, Әлмәт районына - 5%, Бөгелмә районына - 8%, Бөгелмә шәһәренә - 10%, Зәй районына - 19%, Лениногорск районына - 12%, Түбән Кама шәһәренә - 7%, Сарман районына - 3%, Баулы районына - 20%, Октябрь районына - 16%, Тукай районына - 16%;

- физик затлардан керемгә салым - 11%лы ставка буенча; ә түбәндәге территорияләрнең бюджетына 11%лы ставка буенча керүче салым контингентыннан: Әлмәт районына - 18%, Зәй районына - 59%, Түбән Кама шәһәренә - 45%, Сарман районына - 28%, Азнакай районына - 61%, Баулы районына - 50%, Бөгелмә районына -10%, Бөгелмә шәһәренә- 51 %, Лениногорск районына - 85%;

- предприятиеләрнең һәм оешмаларның милкәтенә салым - 100% күләмендә;

Азнакай районына - 40%, Әлмәт районына -50%, Баулы районына - 50%, Бөгелмә районына - 31%, Зәй районына - 50%, Лениногорск районына - 14%, Октябрь районына - 47%, Сарман районына - 26%, Тукай районына - 96%, Азнакай шәһәренә - 79%, Бөгелмә шәһәренә - 50%, Түбән Кама шәһәренә - 51%, Чистай шәһәренә - 53%.

13 статья. 1996 елда районнарның һәм шәһәрләрнең бюджетларына аракы һәм ликерлы аракы акцизлары акцизлар керемнәренең гомуми суммасыннан түбәндәге процентларда тапшырыла:

Биектау районына - 20%, Мамадыш районына - 20%, Минзәлә районына - 20%, Сарман районына - 4%, Бөгелмә шәһәренә -20%, Чистай шәһәренә - 14%, Казан шәһәренә - 20%.

14 статья. 1996 елгы республика бюджетында агымдагы чыгымнарны финанслау өчен ассигнованиеләрнең гомуми күләмен - 6.327735 млн. сум итеп, үсеш бюджетын финанслау өчен, капитал салуларны да кертеп, 982800 млн.сум итеп билгеләргә.

15 статья. 1996 елда республика бюджетыннан 7310535 млн.сум күләмендә түбәндәге максатларга юнәлтергә:

(млн.сумнарда)

| | Барысы | шул исәптән агымдагы чыгымнар бюджеты | шул исәптән үсеш бюджеты |
|---|---|---|---|
| 1. Дәүләт идарәсенә | 125500 | 125500 | |
| 2. Фән һәм архив учреждениеләренә | 20450 | 19650 | 800 |
| 3. Сәнәгатькә, энергетикага һәм төзелешкә | | | |
| - "Таттөзелешгазлаштыру" РГПга | 25000 | 25000 | |
| - ягулык сәнәгатенә | 2320 | 2320 | |
| - ТТК өчен торак йортлар төзүнең үакыйммәте үсешен компенсацияләүгә | 1500 | | 1500 |
| - капитал салуларга, | 619000 | | 619000 |
| шул исәптән "АлАЗ"га | 120000 | | 120000 |
| - проект эшләренә | 300 | | 300 |
| 4. Авыл хуҗалыгы | | | |
| - Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына, | 778224 | 648924 | 129300 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | шул исәптән: | | | |
| | - җирләрне тамырдан яхшыртуга | 186000 | 186000 | |
| | - тапшырылган терлекчелек продукциясен дотацияләүгә | 300000 | 300000 | |
| | - Ветеринариянең баш идарәсенә | 17350 | 13850 | 3500 |
| | - җир өчен түләү исәбеннән чыгымнарга | 51724 | 51724 | |
| | - икмәкне дотацияләүгә | 47000 | 47000 | |
| | - кире кайтарып бирү шарты белән түбәндәгеләр өчен бирелә торган акчалар: азык-төлек бодае сатып алуга | 423000 | 423000 | |
| | - республика азык-төлек фондына авыл хуҗалыгы продукциясен сатып алу өчен | 349000 | 349000 | |
| 5. | Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклауга: | | | |
| | - урман хуҗалыгына | 72000 | 62000 | 10000 |
| | - әйләнә-тирә мохитне саклауга | 35000 | 7500 | 27500 |
| 6. | Транспортка: | | | |
| | - автомобиль транспортына | 68220 | 42220 | 26000 |
| | - һава юлы транспортына | 5700 | 5700 | |
| | - тимер юлы транспортына | 25200 | 25200 | |
| | - су юлы транспортына | 12000 | 12000 | |
| 7. | Торак-коммуналь хуҗалыгына: | | | |
| | - торак-коммуналь хуҗалыгына | 48140 | 48140 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | - янадан тапшырылучы ведомство торак фондын һәм җәмгыяви-мәдәни өлкә объектларын тотуга | 500000 | 500000 | |
| 8. | Мәгарифкә | 218387 | 170387 | 48000 |
| 9. | Мәдәнияткә: | | | |
| | - мәдәнияткә һәм сәнгатькә | 94616 | 71816 | 22800 |
| | - кинематографиягә | 18285 | 18285 | |
| 10. | "Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында" Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру буенча гамәлләргә | 5280 | 5280 | |
| 11. | Массакүләм мәгълүмат чараларына: | | | |
| | - телевидение һәм радиотапшыруларга | 26300 | 23500 | 2800 |
| | - көндәлек матбугатка һәм нәшриятларга | 34596 | 34596 | |
| 12. | Сәламәтлек саклауга һәм физик тәрбиягә: | | | |
| | - сәламәтлек саклауга | 453000 | 371100 | 81900 |
| | - Санэпидкүзәтү буенча дәүләт комитетына | 62800 | 57500 | 5300 |
| | - физик тәрбиягә һәм спортка | 16550 | 16550 | |
| 13. | Җәмгыяви сәясәткә: | | | |
| | - җәмгыяви тәэминат учреждениеләренә | 52703 | 50803 | 1900 |
| | - яшьләр сәясәтенә | 9098 | 6898 | 2200 |
| | - җәмгыяви яклау гамәлләренә | 219000 | 219000 | |

14. Башка чыгымнарга:

| | | |
|---|---|---|
| - Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең резерв фондына | 33954 | 33954 |
| - республиканың кыска вакытлы облигацияләрен түләүгә | 341000 | 341000 |
| - төрле чыгымнарга | 606915 | 606915 |
| - түбәнгерәк бюджетларга дотацияләргә | 1241423 | 1241423 |
| Бәяләр индексын билгеләү һәм 1995 елдан күчә торган бурычларны каплау буенча фаразлы карашка бәйле резерв | 350000 | 350000 |

16 статья. 1996 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советын, дәүләт хакимиятенең башкарма органнарын һәм хөкем органнарын тоту өчен чыгымнарны 125500 млн.сум күләмендә расларга, шул исәптән:

(млн.сумнарда)

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советын, аның Президиумын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратын, даими рәвештә эшләүче халык депутатларын тотуга | 18663 |
| Татарстан Республикасы халык депутатларына депутат вәкаләтләрен үтәүгә бәйле чыгымнарны каплауга | 312 |
| Закон проектларын эшләү һәм аларга экспертиза үткәрүгә бәйле чыгымнарга | 1000 |

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советының зур залын реконструкцияләү өчен чыгымнарга | 1500 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләрен үткәрүгә бәйле чыгымнарга | 2000 |
| Татарстан Республикасы Президенты, Президент Аппараты эшчәнлеген финанслауга | 9640 |
| Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны үткәрүгә, | 3000 |
| шул исәптән Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясен тотуга | 471 |
| Татарстан Республикасының Конституция күзәтү комитетын тотуга | 468 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Парламент контроле комитетын тотуга | 1027 |
| Татарстан Республикасы Министрлар кабинетын тотуга | 10332 |
| Татарстан Республикасы министрлыкларын, ведомстволарын һәм аларның органнарын тотуга | 71000 |
| Татарстан Республикасының даими вәкиллекләрен тотуга | 4187 |

240



| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Югары арбитраж судын тотуга | 2371 |

17 статья. Бюджет тарафыннан каралган гамәлләрнең әзлекле финанслануын тәэмин итү йөзеннән 1996 елда Татарстан Республикасының республика бюджетыннан районнар һәм шәһәрләр бюджетларына 1241423 млн.сум күләмендә дотация бүлеп бирергә, шул исәптән:

(млн.сумнарда)

| | |
|---|---|
| Аксубай районы | 31600 |
| Актаныш | 32640 |
| Алексеевск | 23929 |
| Апас | 23336 |
| Алабуга | 33431 |
| Арча | 37329 |
| Балтач | 25305 |
| Балык Бистәсе | 31559 |
| Биектау | 15700 |
| Буа | 29768 |
| Зеленодол | 28542 |
| Кайбыч | 15565 |
| Кама Тамагы | 18041 |
| Кукмара | 43950 |
| Лаеш | 26849 |
| Мамадыш | 36556 |
| Менделеевск | 18629 |
| Минзәлә | 718 |
| Мөслим | 25277 |
| Питрәч | 29037 |
| Саба | 30958 |
| Спас | 31277 |
| Теләче | 14180 |
| Тәтеш | 29716 |
| Түбән Кама | 51021 |
| Чирмешән | 20613 |
| Чистай | 20167 |

248



| | |
|---|---|
| Чүпрәле | 26800 |
| Югары Ослан | 18651 |
| Ютазы | 6852 |
| Яңа Чишмә | 18435 |
| Әгерҗе | 23084 |
| Әлки | 30072 |
| Әтнә | 16374 |
| Зеленодол шәһәре | 39301 |
| Чаллы шәһәре | 99751 |
| Казан шәһәре | 227128 |

18 статья. 1997 елның 1 гыйнварена Татарстан Республикасы республика бюджетының касса әйләнешендәге акчаларын 20 млрд.сум күләмендә расларга.

19 статья. 1996 елда Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына башкарма хакимиятнең республика органнары хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарларны кабул итмәскә.

20 статья. 1996 елга Татарстан Республикасы республика бюджетының тулы күләмдә финанслана торган яклanучан агымдагы чыгымнарының түбәндәге исемлеген расларга:

Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондының җәмгыяви иминлек кертемнәрен һәм түләүләрен дә исәпкә алып, хезмәт хакы; стипендияләр; дәүләт пособиеләре, балаларга пособиеләр түләү һәм мәктәп балаларын туклandыруга дотацияләр, халыкка башка җәмгыяви һәм компенсация түләүләре; туклandыру; медикаментлар һәм яраларны бәйләү чаралары сатып алу; җирле бюджетка хезмәт хакы түләү өчен бирелгән дотацияләр.

21 статья. 1996 елга Татарстан Республикасы республика бюджетының әлеге Законның 1 статьясында билгеләнгән суммадан артыграк алынган өстәмә керемнәре, әлеге Законның 15 статьясында каралган чыгымнарны статьяда билгеләнгән өлешләрдәгечә арттыруга юнәлдерелә дип билгеләргә.

22 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты һәм Татарстан Республикасы Милли банкы 1996 елда Татарстан Республикасының республика һәм җирле бюджетлары чыгымнарының һәм керемнәренең исәп-хисабы, түләеше системасын оештыруны һәм аның нәтиҗәле эшен тәэмин итәргә тиеш.

Бюджетларның касса түләеше буенча гамәлләре, комиссион түләүләр алынмаган килеш, Милли банк һәм аның кушуы буенча башка банклар тарафыннан башкарыла дип билгеләргә.

23 статья. Татарстан Республикасы республика бюджетының кайбер бүлекләре буенча 1995 елда җитәрлек финансланмау барыстик әлеге Законның 15 статьясында билгеләнгән 1996 елгы республика бюджеты ассигнованиеләре хисабына һәм шул чикләрдә генә компенсацияләнә дип билгеләргә.

24 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессиясендә квартал саен мәгълүмат биреп, кирәк очракларда өстәлгән бәяләргә салым һәм табышка салым буенча ташламалар билгеләүне рөхсәт итәргә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

N 347

Казан шәһәре